Татарстан Республикасы  Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел №4

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы  Иске Суркино авыл җирлеге
Яңа Суркино авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 14 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Яңа Суркино авылының Урман һәм Елга арты урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Мәктәп урамы, 9А йорты.

2. 2019 елның 17 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Яңа Суркино авылының Мәктәп һәм Үзәк урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Суркино авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Үзәк урамы, 12А йорты.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: территорияне төзекләндерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?”

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Суркино, Үзәк урамы, 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә). .

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Иске Суркино
авыл җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев